ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасы Җир кодексының 34 һәм 40 статьяларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 23 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Җир кодексына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 41 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 60 (I өлеш); 2020, № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 57 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 34 статьяда:

а) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Крестьян (фермер) хуҗалыгы үз эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен бирелә торган дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлегенең иң чик минималь күләме 2,3 гектар тәшкил итә.

Әлеге пункт таләпләре федераль законнарда каралган очракларга кагылмый.»;

б) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Крестьян (фермер) хуҗалыгы үз эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен бирелә торган дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлегенең иң чик максималь күләме 500 гектар тәшкил итә.»;

в) 4 пунктта «ике гектарга» сүзләрен «2,3 гектарга» сүзләренә алмаштырырга;

2) 40 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән барлыкка килә торган яңа җир кишәрлегенең минималь күләме 2,3 гектар тәшкил итә.

2,3 гектарга тигез яки аннан зуррак мәйданлы җир кишәрлеген барлыкка китерү мөмкин булмаса, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән барлыкка килә торган яңа җир кишәрлегенең минималь күләме барлыкка килергә мөмкин булган җир кишәрлегенең максималь мәйданына тигез итеп билгеләнә.

Әлеге пункт таләпләре федераль законнарда каралган очракларга кагылмый.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2022 ел, 29 сентябрь
№ 54-ТРЗ